**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАРАТЛЫ-КИЧУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАРАТЛЫ-КИЧУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 12** **24.09.2026 ел**

**Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә Башлангыч хәрби исәпкә алуны оештыру һәм башкару турында Нигезләмәне раслау турында**

1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы «Оборона турында» Федераль закон, 1997 елның 26 февралендәге «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизация турында» 31-ФЗ номерлы Федераль закон, 1998 елның 28 мартындагы «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 53-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге «Хәрби исәп турында Нигезләмәне раслау турында» 719 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Башкарма комитеты КАРАР ЧЫГАРА:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә Башлангыч хәрби исәпкә алуны оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).
2. Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә гражданнарның башлангыч хәрби исәпкә алу буенча җаваплы затның вазыйфаи инструкциясен расларга (2 нче кушымта).
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.:

-Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 09 гыйнварындагы 5 номерлы «Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә гражданнарның башлангыч хәрби исәпкә алуны оештыру һәм алып бару турында» Нигезләмәне раслау турында карарын.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) мизгелдән үз көченә керә.

Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.М.Вәлиев

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү Башкарма комитеты
карарына 1 нче кушымта
24.09.2026 ел № 12

# НИГЕЗЛӘМӘ
## Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә башлангыч хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру

## ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Башлангыч хәрби исәпкә алуны Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең (алга таба – Җирлек) хәрби исәп буенча хезмәткәре башкара.

1.2. Хәрби исәп буенча хезмәткәр үз эшчәнлегендә 1996 елның 31 маендагы № 61-ФЗ «Оборона турында», 1997 елның 26 февралендәге № 31-ФЗ «Россия Федерациясендә мобилизациягә әзерлек һәм мобилизация турында», 1998 елның 28 мартындагы № 53-ФЗ «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 27 ноябрендәге № 719 «Хәрби исәп турында Нигезләмәне раслау турында» карарына, Россиянең Саклану министрлыгы тарафыннан 2017 елның 11 июлендә расланган җирле үзидарә органнарында башлангыч хәрби исәпкә алуны үтәү буенча Методик рекомендацияләргә, Татарстан Республикасының кануннары һәм башка норматив-хокукый актларына, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Уставына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Нигезләмә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

## ТӨП БУРЫЧЛАР

2.1. Хәрби исәпнең төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) Россия Федерациясе кануннары белән билгеләнгәнн хәрби бурычны гражданнар тарафыннан үтәүне тәэмин итү;

б) хәрби исәптә торган гражданнар турындагы хәрби исәп мәгълүматларын документлаштыру;

в) илнең оборонасы һәм дәүләт куркынычсызлыгы мәнфәгатьләре өчен ихтыяҗ булган чакта шаҗәрә мобилизация кеше ресурсларының сан яктан составын һәм сыйфат ягыннан халәтен анализлау;

г) хәрби вакытта мобилизация вакытында Россия Федерациясенең Кораллы көчләре, башка гаскәрләр, хәрби оешмалар һәм органнарның тыныч вакыттан хәрби вакытка күчеш чараларын үткәрү өчен кирәкле булган хәрби әзерлекле гражданнар, запаста булган гражданнарның кирәкле санын әзерләү буенча планлы эш алып бару һәм аларның хәрби вакытта таләп ителә торган дәрәҗәдә тулыландырылуын тәэмин итү.

## ФУНКЦИЯЛӘР

Баштагы хәрби исәп документларында булган мәгълүматларны җыю, саклау һәм эшкәртүне оештыру һәм тәэмин итү максатларында, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары:

3.1. Җирлек территориясендә яшәүче яки вакытлыча (3 айдан артык) торучы, шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча теркәлмәгән гражданнарның, шулай ук запаста булган гражданнарның һәм хәрби хезмәткә чакырылачак гражданнарның башлангыч хәрби исәбен ала;

3.2. Җирлек территориясендә яшәүче яки вакытлыча (3 айдан артык) торучы, шул исәптән яшәү урыны һәм (яки) тору урыны буенча теркәлмәгән һәм хәрби исәпкә куелырга тиешле гражданнарны эчке эшләр органнары белән берлектә ачыклый;

Үз территориясендә урнашкан оешмаларның исәбен алып бара һәм аларда хәрби исәп алып баруны контрольдә тота;

3.4. Башлангыч хәрби исәп документларын Россия Федерациясе Саклану министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формада машина язмасы һәм электрон төрдә алып бара һәм саклый;

3.5. Башлангыч хәрби исәп документларын тиешле хәрби комиссариатлар һәм оешмаларның хәрби исәп документлары белән елга 1 тапкырдан ким булмаганча чагыштыра;

3.6. Башлангыч хәрби исәп документларында булган мәгълүматларга үзгәрешләр кертә һәм 10 эш көне эчендә кертелгән үзгәрешләр турында Россия Федерациясе Саклану министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формада хәрби комиссариатларга хәбәр итә;

3.7. Оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга аларның хәрби исәп, мобилизациягә әзерлек һәм мобилизация бурычларын, Россия Федерациясе кануннары һәм әлеге Нигезләмә белән урнаштырылган бурычларын аңлата, аларның үтәлешен контрольдә тота, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында хәбәр итә;

3.8. Оешмаларның вазыйфаи затлары һәм гражданнар тарафыннан хәрби исәп, мобилизациягә әзерлек һәм мобилизация бурычларын үтәмәү очраклары турында мәгълүматны ачыкланган көннән башлап, 10 эш көне эчендә электрон формада, шул исәптән алыштырыла торган машина күчермәсендә, хәрби комиссариатларга тәкъдим итә;

3.9. Ел саен, 1 февральгә кадәр, узган елда башлангыч хәрби исәпкә алу нәтиҗәләре турында отчетны тиешле хәрби комиссариатларга тәкъдим итә.

## ХОКУКЛАР

4.1. Планлы һәм максатчан эш өчен хәрби исәп буенча хезмәткәр түбәндәге хокукларга ия:

дәүләт хакимиятенең федераль органнарыннан, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оештыру-хокукый формалардан һәм милек формаларыннан бәйсез рәвештә учреждениеләр һәм оешмалардан урнаштырылган тәртиптә сорату һәм алырга кирәкле материаллар һәм мәгълүмат тәкъдим итү;

җирле үзидарә органы хакимиятенең структур бүлекчәләреннән аналитик материалларны, чаралар планы тәкъдимнәрен һәм аларның үтәлеше турында мәгълүматны, шулай йөкләтелгән бурычларны нәтиҗәле үтәү өчен кирәкле булган башка материалларны сорату һәм алу;

үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмат базаларын булдыру;
җирле үзидарә органы белән җитәкчегә аерым эшләрне үтәү өчен контракт нигезендә эшчеләрне җәлеп итү мәсьәләләрен карарга тәкъдим итү;

үз компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча федераль башкару хакимияте органнары, Татарстан Республикасы башкару хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук иҗтимагый берләшмәләр, оешмалар белән урнаштырылган тәртиптә үзара эш алып баруны оештыру һәм хезмәти язышуны тәэмин итү;

## ҖИТӘКЧЕЛЕК

5.1. Хәрби исәп буенча хезмәткәр Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнә һәм вазыйфасыннан азат ителә һәм кушымта буенча эшчәнлек алып бара.

5.2. Хәрби исәп буенча хезмәткәр Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Башкарма комитеты җитәкчесенә турыдан-туры буйсына.

5.3. Хәрби исәп буенча хезмәткәрнең эш урынында булмавы очрагында (отпуск, вакытлыча эшкә яраксызлык, командировка) аны Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль районы Наратлы-Кичү авыл җирлегенең Башкарма комитеты җитәкчесе алыштыра.

Татарстан Республикасының
Минзәлә муниципаль районы
Наратлы-Кичү авыл җирлеге
Башкарма комитетының
карарына 2 нче кушымта
24.09.2026 ел №12

Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә башлангыч хәрби исәп алу буенча җаваплы затның
ВАЗЫЙФАИ ЙӨКЛӘМӘЛӘРЕ

Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә гражданнарның башлангыч хәрби исәбен алу буенча җаваплы зат вазыйфаи зат итеп билгеләнә һәм авыл җирлеге башлыгына буйсына.

Наратлы-Кичү авыл җирлеге территориясендә гражданнарның башлангыч хәрби исәбен алу буенча җаваплы зат үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, гамәлдәге Федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, РФ Хөкүмәтенең норматив хокукый актларына таяна.

Башлангыч хәрби исәпне оештыру һәм алу буенча җаваплы зат җирлектә башлангыч хәрби исәпкә алуны оештыру һәм үтәү өчен җаваплы.

Наратлы-Кичү авыл җирлеге Башкарма комитетына йөкләтелгән бурычларга туры китереп, башлангыч хәрби исәп алу буенча җаваплы зат түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) запаста булган гражданнарның, һәм хәрби хезмәткә чакырылачак гражданнарның, җирлек территориясендә яшәүче яки булган (өч айдан артык вакытка) башлангыч хәрби исәбен алуны үтәргә;

2) җирлек территориясендә яшәүче яки булган (өч айдан артык вакытка) гражданнарның, хәрби исәпкә торырга тиешле булганнарын эчке эшләр органнары белән бергә ачыкларга;

3) җирлек территориясендә урнашкан оешмаларның исәбен алып барырга һәм аларда хәрби исәп алуны контрольдә тотарга;

4) Россия Федерациясенең Саклану министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формада башлангыч хәрби исәп документларын алып барырга һәм сакларга;

5) башлангыч хәрби исәп документларын Минзәлә районы хәрби комиссариатының хәрби исәп документлары белән ел саен кимендә бер тапкыр чагыштырып торырга;

6) башлангыч хәрби исәп документларында булган мәгълүматларга үзгәрешләрне үз вакытында кертергә, һәм Россия Федерациясенең Саклану министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формада 10 эш көне эчендә кертелгән үзгәрешләр турында хәрби комиссариатларга хәбәр итәргә;

7) оешмаларның вазыйфаи затларына һәм гражданнарга, аларның хәрби исәп, мобилизациягә әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын, РФ законнары һәм Хәрби исәп турындагы Нигезләмә белән билгеләнгәнчә, аңлату һәм аларның үтәлешен контрольдә тотарга, шулай ук күрсәтелгән бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылык турында мәгълүмат бирергә;

8) оешмаларның вазыйфаи затларының һәм гражданнарның хәрби исәп, мобилизациягә әзерлек һәм мобилизация буенча бурычларын үтәмәү очраклары турында мәгълүматны 10 эш көне эчендә,

ачыкланган көннән электрон формада, шул исәптән алынма машина күчермәсендә, Минзәлә районы хәрби комиссариатына җиткерергә;

9) хәрби билетларның (хәрби билетлар урынына бирелгән вакытлыча таныклыкларның) яки хәрби хезмәткә чакырылачак гражданнарның таныклыкларының булуын һәм дөреслеген, шулай ук аларда язмаларның дөреслеген, мобилизация язуларының булуын (хәрби билетларда аларның тапшырылуы турында тамга булганда, хәрби җитәкчелеккә булган запастагылар өчен), элекке яшәү урыны буенча гражданнарны хәрби исәптән чыгару турында хәрби исәп документларындагы тамгаларның, Россия Федерациясе гражданнары паспортларындагы аларның хәрби бурыч белән бәйләнеше турында тамгаларны тикшереп торырга;

10) түбәндәгеләрне тутырырга:

- запастагы офицерларның башлангыч исәп карточкалары;

- прапорщикларның, мичманнарның, старшиналарның, сержантларның, солдатларның һәм матросларның запастагы алфавит карточкалары һәм исәп карточкалары (ике данәдә);

- чакырылучыларның башлангыч хәрби исәп карталары.

11) гражданнарның, хәрби исәпкә алыначак гражданнарның документларында булган гаилә хәле, белеме, эш урыны, вазыйфасы, яшәү урыны яки булу урыны турында мәгълүматларны һәм башка кирәкле мәгълүматларны ачыкларга;

12) чакырылучыларны, Минзәлә районы хәрби комиссариатына хәрби исәпкә куелу өчен шәхси килеп күренүнең кирәклеге турында хәбәр итәргә;

13) Минзәлә районы хәрби комиссариатына, хәрби исәп документларында һәм гражданнарның мобилизация язуларында табылган төзәтмәләр, төгәлсезлекләр, ялган язмалар һәм битләрнең тулы булмавы турында мәгълүмат бирергә;

14) җирлек чикләреннән тыш яңа яшәү урынына күчеп, хәрби исәптән чыгарылмыйча киткән гражданнар исемлеген ике атна эчендә төзеп, Минзәлә районы хәрби комиссариатына тапшырырга;

15) хәрби исәптән чыгарылган гражданнарның башлангыч хәрби исәп документларын, Минзәлә районы хәрби комиссариатының исәп мәгълүматлары белән чагыштырыпбетергәннән соң, билгеләнгән тәртиптә юк ителгәнче, сакларга;

16) ел саен, 1 февральгә кадәр, Минзәлә районы хәрби комиссариатына алдагы елда хәрби исәп алу нәтиҗәләре турында отчетлар тапшырырга.